ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья. **Хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының (алга таба – тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары) төп бурычларын, эшчәнлеген оештыру тәртибен, функцияләрен билгели. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җәмәгать тәртибен тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыруда һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итүдә дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтүне оештыру максатларында дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, иҗтимагый һәм башка берләшмәләрнең, шулай ук гражданнарның үзара эшчәнлеге рәвеше булып тора.

## 2 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары һәм җирле үзидарә органнарының хокукый актлары тәшкил итә.

## 3 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының төп бурычлары түбәндәгеләргә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт:
1) җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә;

2) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауга, аларның җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тотуын тикшереп торуны гамәлгә ашыруга, балигъ булмаганнарның яшәү урыны буенча культуралы ялын оештыруга;

3) торак йортлардан, шулай ук йорт янындагы һәм ишегалды территорияләреннән файдалану, аларны карап тоту, эксплуатацияләү тәртибен үтәүгә;

4) торак йортларның һәм торак зоналарында урнашкан башка объектларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә;

5) төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүгә, торак зоналарда төзекләндерү объектларын һәм яшел үсентеләрне саклауга;

6) йорт хайваннарын тоту кагыйдәләрен үтәүгә.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары үзләренә беркетелгән территорияләрдә түбәндәгеләрне башкара:

1) җәмәгать тәртибен ныгыту буенча тәкъдимнәр эшләүне һәм аларны дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләренә тапшыруны;

2) хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү, шул исәптән халыкка мәгълүмат бирү һәм хокук белемнәрен пропагандалау чараларын үткәрүне;

3) халыкка консультатив ярдәм күрсәтүне.

4 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге принциплары**

Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) законлылык;

2) ихтыярыйлык;

3) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өстенлеге;

4) эчке эшләр органнары (полиция), башка хокук саклау органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен алмаштыруга юл куелмау;

5) хәбәрдарлык һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге турындагы мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуы;

6) хокукка каршы янаулардан һәркемнең закон белән тыелмаган барлык ысуллар ярдәмендә үз-үзен яклау хокукы;

7) эчке эшләр органнары (полиция), башка хокук саклау органнары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлек;

8) гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган өчен вазыйфаи затларның һәм гражданнарның җаваплылыгы.

5 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын оештыру тәртибе һәм аларның составы**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары җирле үзидарә органнары карары белән оештырыла.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктын оештыру турындагы карарда аның исеме, аңа беркетелгән территория, аны урнаштыру өчен бирелә торган урын һәм бүлеп бирелә торган матди-техник чаралар хакында, шулай ук җирле үзидарә органының тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлеген тәэмин итүче, законнар белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи заты (алга таба – вәкаләтле вазыйфаи зат) һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшендә катнашучыларның санлы составы хакында мәгълүматлар булырга тиеш.

3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшендә катнашучыларның санлы составы тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә яшәүче халык санын, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә урнашкан оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр, шул исәптән халык дружиналары, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары санын исәпкә алып билгеләнә. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының персональ составы вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә.

4. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар составына, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләреннән тыш, гражданнар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр вәкилләре керә ала.

5. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар үз вазыйфаларын түләүсез һәм ирекле нигездә башкара.

6. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын оештыруның тәкъдим ителә торган критерийлары, шул исәптән тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә яшәүче халык санына, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә урнашкан оешмалар, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр санына карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6 статья. **Гражданнарның тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә катнашуы**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә 18 яшькә җиткән, үзләре теләк белдергән һәм үзләренең әхлакый сыйфатлары, сәламәтлеге хәле буенча тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә катнашырга сәләтле булган Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә түбәндәгеләр катнаша алмый:

1) кире алынмаган яисә бетмәгән хөкем ителүе булган затлар;

2) үзләренә карата җинаять эзәрлекләве башкарыла торган затлар;

3) белә торып кылган җинаятьләр өчен элек хөкем ителгән затлар;

4) «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экстремистлык эшчәнлегендә яисә террорчылыкта катнашулары турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән затлар;

5) үз көченә кергән суд карары белән гамәлләрендә экстремистлык эшчәнлеге билгеләре булуы билгеләнгән затлар;

6) психик авырулардан интегүче, наркомания яисә эчкечелек белән авыручы затлар;

7) үз көченә кергән суд карары белән хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикле дип танылган затлар;

8) чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) булган затлар.

7 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары функцияләре**

1. Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты:

1) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибенең һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрнең торышын өйрәнә, үзенә беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча тиешле дәүләт органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына керә торган мәгълүматны анализлый һәм аны вәкаләтле участок полициясе хезмәткәре игътибарына җиткерә, ә кичектереп булмый торган мәгълүмат алганда, тиешле эчке эшләр органының дежур частенә хәбәр итә;

3) үзенә беркетелгән территориядә җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләргә ярдәм күрсәтә, алар белән хезмәттәшлек итә;

4) үзенә беркетелгән территориядә булган хокук бозуларны кылган затларны законнар нигезендә җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен мондый хокук бозулар хакындагы мәгълүматны һәм материалларны дәүләт хакимияте органнарына җибәрә;

5) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына беркетелгән территориядә халык арасында хокук белемнәрен пропагандалауны гамәлгә ашыра;

6) вәкаләтле участок полициясе хезмәткәрләренә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре хезмәткәрләренә гражданнарны кабул итүдә ярдәм күрсәтә;

7) гражданнарны ирекле нигездә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенә җәлеп итә;

8) үзенә беркетелгән территориядә хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү чараларын үткәрүгә ярдәм күрсәтә;

9) җирле үзидарә органнары тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә торган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә;

2) вәкаләтле вазыйфаи затның тәртип саклау буенча җәмәгать пунктына йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыруга бәйле булган йөкләмәләрен һәм күрсәтмәләрен башкарырга.

3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) гражданнардан хокук тәртибен бозуны туктатуны таләп итәргә;

2) хокук бозулар фактларын теркәргә һәм алар турында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларына һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына хәбәр итәргә;

3) эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затларына хокук бозуларны бетерүдә ярдәм күрсәтергә.

8 статья. **Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары белән үзара эшчәнлеге**

1. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары белән үзара эшчәнлекне түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыралар:

1) аларның эшчәнлек тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар чыгару;

3) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге өчен аларга беркетелгән территорияләрдә хокук тәртибе торышы турындагы кирәкле мәгълүмат бирү;

4) тәртип саклау буенча җәмәгать пункты эшчәнлегендә актив катнашучы гражданнарны бүләкләү;

5) хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү чараларын бергәләп үткәрү.

2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә:

1) җәмәгать тәртибен тәэмин итү мәсьәләләре буенча кертелгән тәкъдимнәрне карыйлар;

2) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшендә катнашучылар ачыклаган хокук бозуларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча законнар нигезендә чаралар күрәләр;

3) тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының эшчәнлекләре турындагы мәсьәләләр буенча кабул ителә торган карарлар хакында аларга хәбәр итәләр.

9 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген матди һәм финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнары тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеге өчен кирәкле урыннар, техник һәм башка матди чаралар бүлеп бирергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслашырга хокуклы.

3. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген матди һәм финанс ягыннан тәэмин итү шулай ук законнарга каршы килми торган тәртиптә һәм рәвешләрдә оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр акчалары, башка кертемнәр исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

10 статья. **Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә актив катнашучы затларны бүләкләү**

Вәкаләтле вазыйфаи зат тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегендә актив катнашучы затларны бүләкләү турында дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар җитәкчеләренә үтенечнамә юлларга хокуклы.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны ул үз көченә кергән көненнән алып алты ай вакыт эчендә кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 33-ТРЗ